| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2021 Казан ш. № 520-110/тэ-2021

Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясе өчен 2022-2024 елга тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «ТГК-16» АҖ) тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга, җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2021 № 520-110/тэ-2021
карарына кушымта

Зеленодольск муниципаль районында «ТГК-16» АҖ тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2022-2024 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| 1 | «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Зеленодольск муниципаль районы | | | | | | | |
| | Бер ставкалы тариф, сум/Гкал | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 809,24 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 838,38 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 785,05 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 835,56 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 835,56 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 868,98 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге